МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.06.2022 г. Казань № 18-75

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.05.2008 ел, № 18-55 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт бурычы кенәгәсен алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.05.2008 ел, № 18-55 боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 21.04.2020 ел, № 18-49 боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт бурычы кенәгәсен алып бару тәртибенә кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Бу боерыкның рәсми басылып чыккан көннән соң үз көченә керүен һәм Татарстан Республикасы дәүләт бурычы составында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен учетка алганда 2022 елның 1 гыйнварыннан килеп чыгучы хокукый мөнәсәбәтләргә кагылуын билгеләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгы-
ның

18.06.2022 ел, №18-75
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.05.2008 ел, № 18-55 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт бурычы кенәгәсен алып бару тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр

1. 5 пунктта:

а) 2 пунктчада:

алтынчы абзацта “алынган” дигән сүзне “җәлеп ителгән” дигән сүзләргә алыштырырга;

тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 4 пунктчада:

бишенче абзацта “бирелгән” дигән сүзне “җәлеп ителгән” дигән сүзләргә алыштырырга;

алтынчы абзацта “биргән органнар турында мәгълүматлар” дигән сүзләрне “шуннан бирелгән бюджет” дигән сүзләргә алыштырырга;

в) 5 пунктчаның ун беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт гарантияләреннән килеп чыгучы йөкләмәләрне тулысынча яки өлешчә үтәү, туктату турында мәгълүматлар;».

2. 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре турында мәгълүматлар (Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрдән тыш) Бурыч кенәгәсенә тиешле йөкләмә килеп чыкканнан соң биш эш көненнән артмаган срокта кертелә.

Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурыч йөкләмәләре турында мәгълүматлар Бурыч кенәгәсенә Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләренең фактта килеп чыгуы (артуы) яки туктатылуы (киметелүе) турында мәгълүматлар алынганнан соң биш эш көне эчендә кертелә.».

3. 12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

4. 16 пунктның уникенче абзацының «а» пунктчасында “бирелгән” дигән сүзне “бирелгәннәр” дигән сүзгә алыштырырга.

5. Әлеге Тәртипкә № 2 кушымтадагы таблицага 7 графадан соң «Җәлеп ителгән кредит күләме» $7^1$ графасын өстәргә.

6. Әлеге Тәртипкә № 3 кушымтадагы таблицага 7 графадан соң «Җәлеп ителгән бюджет кредиты күләме» $7^1$ графасын өстәргә.

7. Әлеге Тәртипкә № 3 кушымтадагы таблицада:

5 графадан соң “Дәүләт гарантиясенең чик суммасы” $5^1$ графасын өстәргә;

14 графа атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт гарантиясеннән килеп чыгучы йөкләмәләр гарантын фактта үтәү күләме (сумнарда)»;

16 графа атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт гарантиясе белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләренең йөкләмә валютасында фактагы күләме»;

17 графа атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт гарантиясеннән килеп чыгучы йөкләмәләр күләме (сумнарда)».